Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Аппак авыл Советы

КАРАРЫ

26 сентябрь 2023 ел № 82

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 132 номерлы Аппак авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Аппак авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2023 елның 7 сентябрендәге 02-08-01/306 номерлы протестын карап

Аппак авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 132 номерлы «Аппак авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Аппак авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә хакында»гы карарына (2021 елның 21 маендагы 23 номерлы, 2022 елның 09 июнендәгы 48 номерлы карарлары белән керткән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. карарга кушымтада 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Граждан үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында муниципаль хезмәткә килгәндә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр тапшырганда йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда күрсәтелгән гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора».

Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең)

һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырган очракта, йә ялган булмаган белешмәләрне тапшырмау муниципаль хезмәткәрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Аппак авылы, Тынычлык урамы, 71 нче йорт; Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Аппак
авыл җирлеге башлыгы В.Н.Горбунова